РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
НИЖНЕКАМСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

Тел./факс: (8555) 42-42-66. E-mail: Gorsovet.Nk@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2023 елның 13 ноябре № 45

«Түбән Кама шәһәренең бюджет-финанс сәясәтен билгеләүче нигезләмәләрне раслау турында» 2009 елның 28 гыйнварындагы 5 номерлы Түбән Кама шәһәр Советы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе закон актларының аерым нигезләмәләре үз көчләрен югалтуын тану турында» 2023 елның 4 августындагы 416-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Түбән Кама шәһәр Советы

КАРАР БИРӘ:

1. «Түбән Кама шәһәренең бюджет-финанс сәясәтен билгеләүче нигезләмәләрне раслау турында» 2009 елның 28 гыйнварындагы 5 номерлы Түбән Кама шәһәр Советы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

карарга 1 нче кушымтада

7 бүлекнең 4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «4. Бюджет чыгымнарының максатчан статьялары исемлеге һәм кодлары Россия Федерациясе Бюджет кодексының 18 статьясының 3 һәм 4 пунктлары нигезләмәләрен исәпкә алып, бюджет һәм финанслар департаменты тарафыннан билгеләнә, әгәр Россия Федерациясе Бюджет кодексында башкасы билгеләнмәгән булса.»;

27 бүлекнең 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Муниципаль программаларны гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итүгә бюджет ассигнованиеләре күләме Башкарма комитет билгеләгән муниципаль программалар исемлеге һәм структурасы нигезендә һәр программага туры килгән бюджет чыгымнарының максатчан статьясы буенча шәһәр Советының шәһәр бюджеты турында карары белән раслана.

Чираттагы финанс елыннан башлап гамәлгә ашыру өчен тәкъдим ителгән муниципаль программалар, шулай ук элек расланган муниципаль программаларга үзгәрешләр Башкарма комитет билгеләгән тәртиптә һәм срокларда расланырга тиеш.»;

27 бүлекнең 4 пунктын үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга һәм Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Түбән Кама шәһәр Советының бюджет сәясәте һәм икътисади үсеш буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Түбән Кама шәһәре Мэры вазыйфаларын
башкаручы, Мэр урынбасары М.В. Камелина